Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге Сарысаз-Тәкермән авылы
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 14.11.2019

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Сарысаз-Тәкермән авылы халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2020 елда үзара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы: - Сарысаз Тәкермән торак пунктының Карл Маркс, Чапаев урамы буенча юлларга вак таш җәю (таш ташу);
- Сарысаз Тәкермән торак пунктының җирле әһәмияттәге юлларын кышын кардан чистарту;
- Сарысаз Тәкермән торак пунктында Сабантуй бәйрәмен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
-Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Сарысаз Тәкермән торак пунктларында урам утларын ремонтлау (лампаларны алыштыру)
ӘЙЕ ЮК”

соравы буенча 2019 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде,
2019 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 148 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 121 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 121 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә булды:
1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныrга.
2. «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2020 елда үзара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

- Сарысаз-Тәкермән торак пунктының Карл Маркс, Чапаев урамы буенча юлларга вак таш җәю (таш ташу);
-Сарысаз-Тәкермән торак пунктының җирле әһәмияттәге юлларын кышын кардан чистарту;
- Сарысаз-Тәкермән торак пунктында Сабантуй бәйрәмен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
-Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу;
-Сарысаз-Тәкермән торак пунктында урам утларын ремонтлау (лампаларны алыштыру)» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга («әйе» - 121, «юк»-0).

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Сарысаз-Тәкермән авылы, Карл Маркс урамы, 1а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р. Ә. Исламова